ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 585-129/тэ-2022

«Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-90/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023 елга җылылык энергиясе югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе (егәрлеге) сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә озак сроклы тарифларга 2023 елга төзәтмә кертү максатларында, җайга салынулы оешманың кирәкле планлаштырылган тулай табышын тәгаенләштереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган

җылылык энергиясенә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 19.12.2018 № 5-90/тэ карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.12.2019 № 5-124/тэ, 17.12.2020 № 524-102/тэ-2020, 16.12.2021 № 646-124/тэ-2021 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кушымтасына, аны яңа редакциядә биреп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-90/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 16.12.2021 № 646-124/тэ-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 5-90/тэ карарына кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.11.2022 № 585-129/тэ-2022 карары редакциясендә)

## «Татэнерго» АҖ тарафыннан җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясен сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә 2019-2023 елларга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | басым астында сайланма пар | | | | кискен һәм редукциял әнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| 1 | «Татэнерго» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Казан шәһәре | | | | | | | |
| | бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 757,30 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 794,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 794,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 876,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 876,08 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 972,28 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 866,79 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап | 904,32 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 31.12.2022 кадәр | | | | | | |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 977,59 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Түбән Кама шәһәре, Түбән Кама муниципаль районының Афанас авыл җирлеге һәм Красный Ключ авыл җирлеге | | | | | | | |
| | бер ставкалы тариф, сум/Гкал | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 506,32 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 702,50 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 656,09 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 681,82 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 677,77 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 735,35 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 720,24 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 753,51 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 790,32 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге